**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXXIII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 60**

Тойгелде авылы 27 нче ноябрь 2023 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Тойгелде авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 нчы декабрендәге 9 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында" 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокурорының 2023 елнын 21 ноябрендәге 02-01-12-2023 номерлы норматив-хокукый актын кабул итү кирәклеге турындагы мәгълүматне үтәү өчен, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелдеавыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Тойгелде авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 нчы декабрендәге 9 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 35 статьяның 5 өлешенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасында бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) Татарстан Республикасы Советына юлламасы нигезләмәләре;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тойгелде авыл
җирлеге башлыгы урынбасары Минһаҗева Г.Р.